**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Об учреждении почетного знака «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»**

В целях признания заслуг в сфере добровольческой (волонтерской) деятельности в Республике Татарстан **постановляю:**

1. Учредить почетный знак «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан».

2. Утвердить:

Положение о почетном знаке «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» (приложение № 1);

описание почетного знака «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» (приложение № 2);

рисунок почетного знака «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» (приложение № 3);

описание удостоверения к почетному знаку «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» (приложение № 4).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 июня 2026 года
№ 520

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «30» июня 2026 года

№ 520

# ПОЛОЖЕНИЕ
## о почетном знаке «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»

### I. Общие положения

1. Почетный знак «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» (далее – Почетный знак) является формой поощрения лиц, осуществляющих добровольческую (волонтерскую) деятельность в Республике Татарстан.

2. Почетным знаком могут быть поощрены граждане Российской Федерации, иностранные граждане, лица без гражданства, внесшие значительный вклад в развитие добровольческого (волонтерского) движения в Республике Татарстан (далее – доброволец (волонтер), а также соответствующие одному из следующих требований:

а) наличие заслуг в организации деятельности добровольцев (волонтеров), направленной на решение общественно полезных задач в Республике Татарстан;

б) осуществление добровольческой (волонтерской) деятельности не менее пяти лет.

Условие о продолжительности осуществления добровольческой (волонтерской) деятельности, предусмотренное подпунктом «б» настоящего пункта, не распространяется на добровольческую (волонтерскую) деятельность, направленную на оказание поддержки военнослужащим – участникам боевых действий.

### II. Порядок поощрения Почетным знаком

3. Ходатайство о поощрении Почетным знаком (далее – ходатайство) возбуждается организациями, общественными объединениями, государственными органами Республики Татарстан и органами местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан.

4. При возбуждении ходатайства заполняется представление по форме согласно приложению к настоящему Положению.

Лица, оформляющие и подписывающие представление, обеспечивают достоверность указанных в нем сведений.

5. Ходатайство и представление вносятся организациями, общественными объединениями, государственными органами Республики Татарстан и органами местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, возбудившими ходатайство, в Межведомственный совет по развитию добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан, образованный Кабинетом Министров Республики Татарстан (далее – Межведомственный совет).

6. К ходатайству прилагаются:

а) копия документа, удостоверяющего личность кандидата, представленного к поощрению Почетным знаком (далее – кандидат);

б) согласие кандидата на обработку персональных данных, содержащихся в ходатайстве, представлении и документах, указанных в настоящем пункте, в соответствии со статьей 9 Федерального закона от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных»;

в) копия сведений о добровольческой (волонтерской) деятельности кандидата, размещенных в единой информационной системе в сфере развития добровольчества (волонтерства);

г) справка об отсутствии у кандидата задолженности по налогам, сборам и иным обязательным платежам в бюджеты бюджетной системы Российской Федерации;

д) справка о наличии (об отсутствии) у кандидата судимости и (или) факта уголовного преследования либо о прекращении уголовного преследования.

7. Ходатайство не может быть возбуждено в отношении кандидата, имеющего не снятую или не погашенную в установленном федеральным законом порядке судимость и (или) признанного иностранным агентом в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.

8. Межведомственный совет рассматривает ходатайство и документы, указанные в пункте 6 настоящего Положения, в течение 30 календарных дней со дня их регистрации и принимает одно из следующих решений:

а) обратиться к Раису Республики Татарстан с предложением о поощрении Почетным знаком;

б) отклонить ходатайство.

9. Основаниями для отклонения ходатайства являются:

а) установление недостоверности сведений, содержащихся в ходатайстве;

б) непредставление (представление не в полном объеме) документов, предусмотренных пунктом 6 настоящего Положения;

в) смерть кандидата;

г) осуждение кандидата за совершение преступления на основании приговора суда, вступившего в законную силу (при отмене вступившего в законную силу обвинительного приговора суда и прекращении уголовного дела по реабилитирующим основаниям ходатайство может быть внесено повторно);

д) признание кандидата иностранным агентом в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.

10. Об отклонении ходатайства составляется мотивированное заключение, которое вместе с внесенным ходатайством и приложенными к нему документами направляется в организацию, общественное объединение, государственный орган Республики Татарстан, орган местного самоуправления муниципального образования Республики Татарстан, которые внесли ходатайство.

В случае устранения причин отклонения ходатайства оно может быть внесено повторно.

11. Обращение с предложением о поощрении Почетным знаком направляется Межведомственным советом Раису Республики Татарстан в течение 15 календарных дней со дня принятия соответствующего решения.

К обращению прилагаются:

а) протокол заседания Межведомственного совета;

б) ходатайство и прилагаемые к нему документы;

в) проект указа Раиса Республики Татарстан о поощрении Почетным знаком.

12. Решение о поощрении Почетным знаком принимается Раисом Республики Татарстан на основании предложения, внесенного Межведомственным советом.

13. Поощрение Почетным знаком производится указом Раиса Республики Татарстан, который в целях информирования общественности может быть размещен на официальном сайте Раиса Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» и (или) средствах массовой информации.

14. Повторное поощрение Почетным знаком не производится.

## III. Порядок вручения Почетного знака

15. Вручение Почетного знака осуществляется Раисом Республики Татарстан либо по его поручению иным лицом.

16. Вручение Почетного знака производится в торжественной обстановке добровольцу (волонтеру) лично.

17. В случае смерти добровольца (волонтера), которому при жизни Почетный знак не был вручен, Почетный знак и удостоверение к нему передаются (вручаются) для хранения семье как память без права ношения.

18. О произведенном вручении Почетного знака или его передаче (вручении) семье добровольца (волонтера) составляется протокол, который подписывается лицом, вручившим Почетный знак, или руководителем государственного органа Республики Татарстан, органа местного самоуправления муниципального образования Республики Татарстан, организации, где производилось вручение, и скрепляется соответствующей печатью.

19. Вместе с Почетным знаком добровольцу (волонтеру) выдается удостоверение к Почетному знаку.

20. Организационно-техническое обеспечение деятельности по поощрению Почетным знаком, включая изготовление, хранение Почетных знаков, удостоверений, подготовку и представление на подписание Раису Республики Татарстан удостоверений, а также учет выданных удостоверений, осуществляется Министерством по делам молодежи Республики Татарстан.

Приложение
к Положению о почетном
знаке «За вклад в развитие
добровольчества (волонтерства)
в Республике Татарстан»

## Представление
## к поощрению почетным знаком «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»

1. Фамилия, имя, отчество (при наличии) ________________________________

________________________________________________________________

2. Принадлежность к добровольческой (волонтерской) организации ______________

________________________________________________________________
(полное наименование организации)

3. Место работы, занимаемая должность ________________________________

________________________________________________________________
(полное наименование должности, организации)

________________________________________________________________

4. Пол __________ 5. Дата и место рождения ____________________________

6. Образование ____________________________________________________
(уровень образования, наименование образовательной организации,

________________________________________________________________
год окончания, специальность)

7. Ученая степень, ученое звание, специальное звание ______________________

________________________________________________________________

8. Какими государственными наградами награжден(а), дата награждения __________

________________________________________________________________

9. Другие виды поощрений, награждений ________________________________

________________________________________________________________

10. Стаж добровольческой (волонтерской) деятельности _____________________

11. Трудовая деятельность (включая военную службу):

| Месяц и год (мм.гггг) | | Должность с указанием наименования организации (в соответствии с записями в трудовой книжке) |
|---|---|---|
| поступления | ухода | |
| | | |
| | | |
| | | |

12. Общий стаж работы ______________________________________________

13. Номер контактного телефона (иные способы связи) ____________________

______________________________________________________________

14. Характеристика на представляемого к поощрению с указанием конкретных заслуг

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Руководитель органа, организации,
общественного объединения ________________ ______________________
(подпись) (Ф.И.О.)

М.П. «_____» ___________ 20 ____года

____________

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «30» июня 2026 года

№ 520

# ОПИСАНИЕ
## почетного знака «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»

Почетный знак «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан» изготовлен из латуни с применением методов золочения и эмалирования. Представляет собой круглый золоченый медальон диаметром 20 мм.

В центре медальона изображены две стилизованные ладони, образующие чашу, выполненные эмалями зеленого и красного цветов. Над чашей изображен золоченый цветок тюльпана с тремя лепестками, в центре которого закреплен круглый прозрачный фианит диаметром 2 мм.

По окружности медальона выполнены надписи прописными буквами: в верхней части – на русском языке «ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ ДОБРОВОЛЬЧЕСТВА», в нижней части – на татарском языке «ИХТЫЯРЫЙЛЫК ҮСЕШЕНӘ ӨЛЕШ КЕРТКӘН ӨЧЕН», разделенные точками.

Изображение в центре медальона отделено от надписей выпуклым кантом по окружности диаметром 15 мм.

Все изображения и надписи – рельефные, выступают на 0,3 мм над матовой поверхностью медальона. По периметру медальона выступает гурт. Все выступающие элементы медальона – полированные.

Крепление почетного знака – цанга.

Почетный знак вместе с удостоверением к нему укладывается в футляр бордового цвета с прозрачной крышкой, крепится слева от удостоверения.

___________

Приложение № 3
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «30» июня 2026 года

№ 520

**РИСУНОК**
**почетного знака «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»**



Приложение № 4
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «30» июня 2026 года

№ 520

# ОПИСАНИЕ
## удостоверения к почетному знаку «За вклад в развитие добровольчества (волонтерства) в Республике Татарстан»

Обложка удостоверения изготавливается из плотного картона бордового цвета размером 75 х 105 мм в сложенном виде и 150 х 105 мм в развороте.

На лицевой стороне обложки удостоверения в верхней части располагается золотое изображение Государственного герба Республики Татарстан, под ним – надпись, выполненная золотыми буквами:

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ИХТЫЯРЫЙЛЫК (ВОЛОНТЕРЛЫК)
ҮСЕШЕНӘ ӨЛЕШ КЕРТКӘН ӨЧЕН»
МАКТАУ БИЛГЕСЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ПОЧЕТНОМУ ЗНАКУ
«ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ
ДОБРОВОЛЬЧЕСТВА (ВОЛОНТЕРСТВА)
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН»

Оборотная сторона обложки удостоверения без каких-либо надписей.

На внутренней стороне удостоверения наклеивается бланк вкладыша с текстом на фоне светло-голубой тангирной сетки.

На левой стороне бланка вкладыша располагается надпись:

ТАНЫКЛЫК № _____

________________________________
(фамилиясе)

________________________________
(исеме)

________________________________
(атасының исеме – булган очракта)

«Татарстан Республикасында
ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә
өлеш керткән өчен» мактау билгесе
белән бүләкләнде

*Татарстан Республикасы*
*Рәисе*
М.У.

(Ф.И.О. Раиса Республики Татарстан)

*Татарстан Республикасы Рәисе Указы*

(указывается дата издания Указа Раиса Республики Татарстан)

На правой стороне бланка вкладыша располагается надпись:

УДОСТОВЕРЕНИЕ № _____

________________________________
(фамилия)
________________________________
(имя)
________________________________
(отчество – при наличии)

Поощрен(а)
почетным знаком «За вклад в развитие
добровольчества (волонтерства)
в Республике Татарстан»

*Раис*
*Республики Татарстан*

М.П.

(Ф.И.О. Раиса Республики Татарстан)

*Указ Раиса Республики Татарстан*

(указывается дата издания Указа Раиса Республики Татарстан)

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесен гамәлгә кую турында**

Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә казанышларны тану максатында **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесен гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:
«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында нигезләмәне (1 нче кушымта);
«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесенең тасвирламасы (2 нче кушымта);
«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесенең сурәте (3 нче кушымта);
«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесенә таныклык тасвирламасы (4 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;
үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 30 июнь
№ 520

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «30» июнендәге
520 номерлы Указына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе (алга таба – Мактау билгесе) «Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген башкаручы затларны бүләкләү рәвеше булып тора.

2. Мактау билгесе белән Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) хәрәкәтен үстерүгә күренекле өлеш керткән, шулай ук түбәндәге таләпләрнең берсенә туры килгән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – ихтыярый ярдәмче (волонтер) бүләкләнә ала:

а) Татарстан Республикасында җәмгыять өчен файдалы бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыруда казанышлары булу;

б) кимендә биш ел ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге алып бару.

Әлеге пунктның «б» пунктчасында каралган ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге алып бару дәвамлылыгына куелган шарт хәрби хезмәткәрләргә – хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә кагылмый.

## II. Мактау билгесе белән бүләкләү тәртибе

3. Мактау билгесе белән бүләкләү турында үтенечнамәләр бирүне (алга таба – үтенечнамә) оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары башлый.

4. Үтенечнамә бирү эше башланган очракта әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча тәкъдимнамә тутырыла.

Тәкъдимнамәне рәсмиләштерүче һәм аңа кул куючы затлар анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итә.

5. Үтенечнамәне һәм тәкъдимнамәне үтенечнамә бирү эшен башлаган оешма коллективлары, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырылган Татарстан Республикасында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара советка (алга таба – Ведомствоара совет) юллый.

6. Үтенечнамәгә түбәндәгеләр теркәлә:

а) Мактау билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән кандидатның (алга таба – кандидат) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

б) кандидатның үтенечнамәдә, тәкъдимнамәдә һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә әлеге пунктта күрсәтелгән документларда бирелгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыгы;

в) кандидатның ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге турында мәгълүматларның күчермәсе;

г) кандидатның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә;

д) кандидатның суд җаваплылыгына һәм (яисә) җинаять кылган өчен җаваплылыкка тартылуы (тартылмавы) яисә аңа карата җинаять эшенең туктатылуы турында белешмә.

7. Федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җинаять эше туктатылмаган яисә җинаять кылган өчен җәзасы үтәлмәгән һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә чит ил агенты дип танылган кандидатка карата үтенечнамә бирелә алмый.

8. Ведомствоара совет үтенечнамәне, тәкъдимнамәне һәм әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны алар теркәлгән көннән 30 календарь көн эчендә карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Мактау билгесе белән бүләкләү турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы Рәисенә мөрәҗәгать итәргә;

б) үтенечнамәне кире кагарга.

9. Үтенечнамәне кире кагу өчен нигезләр:

а) үтенечнамәдә бирелгән белешмәләрнең дөрес булмавы ачыклану;

б) әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган документларның бирелмәве (тулы күләмдә бирелмәве);

в) кандидатның вафат булуы;

г) кандидатны законлы көченә кергән суд карары нигезендә җинаять кылган өчен җаваплылыкка тарту (судның законлы көченә кергән гаепләү хөкеме юкка чыгарылган һәм аклый торган нигезләр буенча җинаять эше туктатылган очракта үтенечнамә бирү эше яңадан башлана ала);

д) кандидатның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә чит ил агенты дип танылуы.

10. Үтенечнамәне кире кагу турында нигезле бәяләмә әзерләнә, ул бирелгән үтенечнамә һәм аңа теркәп бирелгән документлар белән бергә үтенечнамә биргән оешмага, иҗтимагый берләшмәгә, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына юллана.

Үтенечнамәне кире кагу сәбәпләре бетерелгән очракта, ул яңадан бирелергә мөмкин.

11. Ведомствоара совет Мактау билгесе белән бүләкләү турында тәкъдим ителгән мөрәҗәгатьне тиешле карар кабул ителгән көннән 15 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә юллый.

Мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

а) Ведомствоара совет утырышы беркетмәсе;

б) үтенечнамә һәм аңа теркәп бирелә торган документлар;

в) Татарстан Республикасы Рәисенең Мактау билгесе белән бүләкләү турында указы проекты.

12. Мактау билгесе белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Рәисе карары Ведомствоара совет тарафыннан кертелгән тәкъдим нигезендә кабул ителә.

13. Мактау билгесе белән бүләкләү Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә башкарыла, ул җәмәгатьчелеккә хәбәр итү максатларында Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

14. Мактау билгесе белән кабаттан бүләкләү каралмаган.

## III. Мактау билгесе белән бүләкләү тәртибе

15. Мактау билгесе Татарстан Республикасы Рәисе яисә аның күрсәтмәсе буенча башка зат тарафыннан тапшырыла.

16. Мактау билгесе ихтыярый ярдәмчегә (волонтерга) тантаналы төстә шәхсән тапшырыла.

17. Ихтыярый ярдәмче (волонтер) вафат булган очракта, аңа Мактау билгесе исән вакытында тапшырылмаган булса, Мактау билгесе һәм таныклык, тагып йөрү хокукыннан башка гына, истәлек буларак саклау өчен аның гаиләсенә бирелә (тапшырыла).

18. Мактау билгесен тапшыру яисә аны гражданның гаиләсенә бирү (тапшыру) турында беркетмә төзелә, ул Мактау билгесен тапшырган зат яисә тапшыру тантанасы узган Татарстан Республикасы дәүләт органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм аңа тиешле мөһер сугыла.

19. Мактау билгесе белән бергә ихтыярый ярдәмчегә (волонтерга) Мактау билгесенә таныклык тапшырыла.

20. Мактау билгесе белән бүләкләү эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне, Мактау билгеләрен, таныклыкларны әзерләүне, саклауны, таныклыкларны Татарстан Республикасы Рәисенә кул куярга әзерләүне һәм бирүне, шулай ук тапшырылган таныклыкларны исәпкә алуны да кертеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә ашыра.

«Татарстан Республикасында
ихтыярыйлык (волонтерлык)
үсешенә өлеш керткән өчен»
мактау билгесе турында
нигезләмәгә
кушымта

**«Татарстан Республикасында**
**ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау**
**билгесе белән бүләкләүгә тәкъдимнамә**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ______________________

______________________________________________

2. Ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмасында торуы ______________________

______________________________________________
(оешманың тулы атамасы)

3. Эшләгән урыны, биләгән вазыйфасы ______________________

______________________________________________
(оешманың, вазыйфасының тулы атамасы)

______________________________________________

4. Җенесе ____________ 5. Туган вакыты һәм урыны ______________________

6. Белеме ______________________
(белем дәрәҗәсе, мәгариф оешмасының атамасы,

______________________________________________
аны тәмамлаган елы, белгечлеге)

7. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, махсус исеме ______________________

______________________________________________

8. Нинди дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, бүләкләү датасы ______________

______________________________________________

9. Башка бүләкләре ______________________

______________________________________________

10. Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге стажы ______________________

11. Хезмәт юлы (хәрби хезмәтне кертеп):

| Ай һәм ел (аа.ееее) | | Оешманың атамасын күрсәтеп, биләгән вазыйфасы (хезмәт кенәгәсендәге язмалар нигезендә) |
|---|---|---|
| эшкә керү | эштән китү | |
| | | |
| | | |
| | | |

13. Элемтә өчен телефон номеры (башка элемтә чаралары) ______________________________

________________________________________________________________________________

14. Тәгаен казанышларын күрсәтеп, бүләкләүгә тәкъдим ителүчегә характеристика

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Орган, оешма, иҗтимагый
берләшмә җитәкчесе ____________________ ________________________
(имзасы) (Ф.И.Аи.)

М.У. 20 ___ елның «____» __________

__________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «30» июнендәге
520 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында**
**ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен»**
**мактау билгесенең**
**ТАСВИРЛАМАСЫ**

«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе алтын йөгертү һәм эмальләү ысулларын кулланып җиздән ясала. Алтын йөгертелгән 20 мм диаметрлы түгәрәк медальон рәвешендә.

Медальонның уртасында яшел һәм кызыл төстәге эмальдән эшләнгән касә рәвешендәге стилизацияләнгән пар уч сурәтләнгән. Касә өстендә алтын йөгертелгән өч таҗлы лалә чәчәге сурәтләнгән, уртасына 2 мм диаметрлы үтә күренмәле түгәрәк фианит беркетелгән.

Медальон әйләнәсендә баш хәрефләр белән түбәндәге сүзләр язылган: өске өлешендә – рус телендә «ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ ДОБРОВОЛЬЧЕСТВА», аскы өлешендә – татар телендә «ИХТЫЯРЫЙЛЫК ҮСЕШЕНӘ ӨЛЕШ КЕРТКӘН ӨЧЕН», язмалар арасында нокта куелган.

Медальонның уртасындагы сурәт белән язмалар арасында әйләнә буйлап 15 мм диаметрлы кабарынкы кайма ясалган.

Барлык рәсемнәр һәм язмалар – кабарынкы, алар медальонның ялтыравыксыз өслегеннән 0,3 мм га калкурак итеп төшерелгән. Медальонның периметры буйлап чите кысаланган. Медальонның барлык кабарынкы элементлары – ялтыратылган.

Билге кыстыргыч ярдәмендә беркетелә.

Билгенең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

Мактау билгесе таныклыгы белән бергә үтә күренмәле капкачлы куе кызыл төстәге футлярга салына, таныклыктан сул якка беркетелә.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «30» июнендәге
520 номерлы Указына
3 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе**
**СУРӘТЕ**




---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «30» июнендәге
520 номерлы Указына
4 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесенә таныклык**
**ТАСВИРЛАМАСЫ**

Таныклык тышлыгы ябык килеш 75 х 105 мм һәм ачып куйгач 150 х 105 мм зурлыктагы куе кызыл төстәге каты катыргыдан эшләнә.

Таныклык тышлыгының алгы ягындагы өске өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтын сурәте төшерелгән, аның астында алтын хәрефләр белән эшләнгән түбәндәге язу урнаштырылган:

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ИХТЫЯРЫЙЛЫК (ВОЛОНТЕРЛЫК)
ҮСЕШЕНӘ ӨЛЕШ КЕРТКӘН ӨЧЕН»
МАКТАУ БИЛГЕСЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ПОЧЕТНОМУ ЗНАКУ
«ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ
ДОБРОВОЛЬЧЕСТВА (ВОЛОНТЕРСТВА)
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН»

Таныклык тышлыгының икенче ягында нинди дә булса язулар юк.

Таныклык тышлыгының эчке ягына сыек зәңгәр тангир челтәрле җирлеккә төшерелгән язмалы өстәмә бланк ябыштырыла.

Өстәмә бланкының сул ягында түбәндәге язу урнаштырылган:

ТАНЫКЛЫК № ____

______________________________
(фамилиясе)
______________________________
(исеме)
______________________________
(атасының исеме – булган очракта)

«Татарстан Республикасында
ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә
өлеш керткән өчен» мактау билгесе
белән бүләкләнде

*Татарстан Республикасы*
*Рәисе*

М.У.

(Татарстан Республикасы Рәисенең Ф.И.А.и.)

*Татарстан Республикасы Рәисе Указы*

(Татарстан Республикасы Рәисе Указы чыккан дата күрсәтелә)

Өстәмә бланкының уң ягында түбәндәге язу урнаштырылган:

УДОСТОВЕРЕНИЕ № ____

______________________________
(фамилия)
______________________________
(имя)
______________________________
(отчество – при наличии)

Поощрен(а)
почетным знаком «За вклад в развитие
добровольчества (волонтерства)
в Республике Татарстан»

*Раис*
*Республики Татарстан*

М.П.

(Ф.И.О. Раиса Республики Татарстан)

*Указ Раиса Республики Татарстан*

(Татарстан Республикасы Рәисе Указы чыккан дата күрсәтелә)

______________